ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӨРЕШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БӨРЕШЛЕ
ТОРАК ПУНКТЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР

1 ноябрь 2024 ел № 1

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бөрешле авыл җирлегенең
Бөрешле торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында" Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 21 октябрендәге 2 номерлы карары белән, 2024 елның 1 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә (сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 116 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 60 кеше; «риза» - гражданнар җыенының 60 катнашучысы тавыш бирә; «каршы» - 0). Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле торак пунктында гражданнар җыены
КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында гражданнар җыены узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. «2025 елда үзара салым акчаларын Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендәге студентлардан, 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан, 80 яшькә җиткән өлкәннәрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорауны расларга һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

1) автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (Бөрешле авылында вак таш түшәлгән юлларда чокырларны ремонтлау; Бөрешле авылында юлларны кардан чистарту);

2) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Бөрешле авылында урам яктыртуына техник хезмәт күрсәтү);

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (Бөрешле авылы территориясен чабу).

3. Әлеге карарны Бөрешле авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми

порталына https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ урнаштырып халыкка җиткерергә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://pravo.tatarstan.ru/ " Бөрешле авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бөрешле авыл җирлеге башлыгы Л.А. Смирнова